Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район
Юлсубино авыл җирлеге Советы

КАРАР №2

Юлсубино авылы 2026 елның 23 гыйнвары

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге Советының 2023 елның 28 апрелендәге “Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында”7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 декабрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль законына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Юлсубино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге Советының 2023 елның 28 апрелендәге “Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында” 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә (18.06.2024 №7, 30.10.2024 №15ред-дә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 пунктның 1 подпунктынн түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Физик затны үлеме яки аны Россия Федерациясе гражданлык процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан итү (мондый физик затка карата банкротлык турында эш кузгатылган очрактан тыш):

Россия Федерациясе Салым кодексының 14 маддәсендәге 3 пунктында һәм 15 маддәсендәге 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелмәгән салымнар буенча, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар өлешендә;

Россия Федерациясе Салым кодексының 14 маддәсендәге 3 пунктында һәм 15 маддәсендәге 1, 2 пунктларында күрсәтелгән салымнар буенча бурыч аның нәселдәнлек мөлкәте бәясеннән артып киткән күләмдә, шул исәптән мирас Россия Федерациясе милкенә күчкән очракта;

Россия Федерациясе Салым кодексының 14 маддәсендәге 3 пунктында һәм 15 маддәсендәге 1, 2 пунктларында күрсәтелгән салымнар буенча бурыч аның нәселдәнлек мөлкәтенең бәясеннән артмаган күләмдә, мондый физик затның

үлеме датасыннан өч ел узгач һәм салым органының мондый мөлкәтне мирас итеп алу факты турында мәгълүматы булмаганда;».

2. Әлеге карар 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы,Юлсубино авылы, Татарстан урамы, 56а,Ямаш авылы Х.Такташ урамы 3в йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Юлсубино авыл җирлеге башлыгы Н.И.Гарипов